СОВЕТ КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Гагарина, д.29, с.Куюк-Ерыкса,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422151

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨЕК-ЕРЫКСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Гагарин ур., 29 нче йорт, Көек-Ерыкса авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422151

тел.(факс): (85563) 3-66-33; e-mail: Kuer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

«28» июль, 2017 ел | № 2-21

Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советының
2016 елның 3 октябрендәге
«Җир салымы турында» 2-14 номерлы
карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр
кертү хакында

2017 елның 21 июнендәге 02-08-02-17 номерлы прокурор протесты, Салым кодексының 391 статьясының 6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге «Җир салымы турында» 2-14 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

- 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым базасын салым түләми торган суммага киметү хокукын раслаучы документлар Россия Федерациясе Салым кодексының 31 нче бүлеге нигезендә салым органына үз сайлавы буенча тапшырыла.».

2. Әлеге карарны «Нократ» («Вятка») район газетасында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында http://madysh.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге башлыгы Ф.Р.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советы рәисе Ф.Р.Шәйхетдинов

СОВЕТ КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ